# REVIEW OF THE BOOK *BARABA TATARS. CHAPTERS OF INTELLECTUAL CULTURE.* F.YU.YUSUPOV, F.S.SAYFULINA, O.R.KHISAMOV, I.G.GUMEROV (KAZAN: KAZAN UNIVERSITY, 2013, 668 P.)

**Gafur Masgutovich Sungatov,**
Republican Centre for the Development of Traditional Culture,
66/33 Pushkin Str., Kazan, 420015, Russia,
gsungatov@mail.ru.

**Fanzilya Khakimovna Zavgarova,**
Republican Centre for the Development of Traditional Culture,
66/33 Pushkin Str., Kazan, 420015, Russia,
fanzila@bk.ru.

The collection titled "Baraba Tatars. Chapters of Intellectual Culture" by F.Yu.Yusupov, F.S.Sayfulina, O.R.Khisamov and I.R.Gumerov deals with the ethnic history and the features of language, traditions, and everyday life of Baraba Tatars, who live in Siberia. The collection includes a scientific and analytical article about the origin of Baraba Tatars, and describes their close linkage with other Turkic tribes of West Siberia since ancient times. Besides the materials which the authors collected in different periods of their research, the collection is supplemented with songs recorded by such scholars as V.V.Radlov, L.V.Dmitrieva, D.G.Tumasheva, and composer A.Klyucharev, who studied Tatar folk music. The collection contains samples of the authentic speech of Baraba Tatars, whose population has been shrinking annually and today, they are among the endangered peoples of Russia. This work provides an opportunity to notice and learn phonetic, lexical and grammatical distinctive features of the Baraba dialect for training broad-minded and well-educated philologists. The collection is also important for historians, ethnographers and those who explore the intellectual culture of the nation.

**Key words:** folklore, Siberian Tatars, the Tatar language, intellectual culture.

Collections are being created with the aim to preserve languages, which include the languages of ethnic groups and certain aspects of their life and folklore. They are seen as an important way of reflecting the changes which have taken place throughout the historical evolution of the nation. It should be mentioned, that these books, published by contemporary linguists, literary scholars, and folklore experts as their common work, are taking their rightful place in Tatar philology. This article presents a review of one of these collections entitled *Baraba Tatars. Chapters of Intellectual Culture*. One of the authors is F.Yu.Yusupov, a scholar who has spent 60 years working on this book and has visited all the regions where the Tatars live. While working on his master's and doctorate theses, he recorded the native speakers' authentic speech, collecting valuable factual material, and published many scientific works based on the results of his research. He has conducted research into Tatar dialectology and has become one of the first Turkic linguists. F.Yu.Yusupov has made a great contribution to the development of Turkic linguistics with his studies based on linguistic geography and comparative-historical methods. He has analyzed the grammar of the Tatar dialect language as a holistic system and has devoted his monographs to phonetics, lexis, and grammar of some Tatar speeches. The second author, F.S.Sayfulina, is a literary theorist who has been teaching in Tobolsk Teacher Training Institute for many years, where she can hear Siberian Tatars' speech every day. Linguist O.R.Khisamov and literary scholar I.R.Gumerov have done a lot to contribute to this publication. This collection is a valuable source for learning the ethnic history of Baraba Tatars, their language peculiarities, traditions, everyday life, and above all, the origin of other Turkic people and their language development.

According to the well-known scholar D.G.Tumasheva, who studied the Siberian Tatars' dialects, the Baraba dialect occupies a middle position among three Siberian Tatar dialects: the Toblsk-Irtysh and the Tom dialects still retaining the features of antiquity. Scholars define the Baraba dialect as a bridge connecting the Tatar language with the ancient Turkic language.

V.V.Radlov recorded the samples of Baraba Tatars' authentic speech and oral folk arts artifacts in the 19th century, and this was an important stage in studying Turkic Tatars. These works of the scholar were appreciated at the time.

Another important aspect of this collection is the idea of publishing the national cultural heritage that was collected by scholars in different centuries based on a single principle. It contains samples from V.V.Radlov's collections, the texts of linguists L.V.Dmitrieva, D.G.Tumasheva and other dialectologists, songs which were recorded by A.Klyucharev, and extremely interesting folk songs from the book by poet M.Sadri *A Trip to the Irtysh*, describing his expedition in the year of 1940. Consequently, this book has aroused great interest on the part of the representatives of science, education and culture from the Novosibirsk region and its authorities.

The book opens with an article exploring the origin of the Baraba Tatars, their fatherland in West Siberia and their connections with other Turkic tribes since ancient times. It deals with the main stages of the Baraba Tatars' development as an ethnos, the cultural and social conditions under which they lived, and a historiographic review of the scientific research connected with this tribe.

According to the introductory article, the population of Baraba Tatars is currently not more than 8,000 people. Kazan Tatars, who moved to the Baraba plains in the 19th and 20th centuries and settled among the local people, should be included in this number. Unfortunately, their numbers are decreasing year by year. This is the reason many international organizations enter Baraba Tatars on the list of the endangered peoples of Russia. With this in mind, the book about the cultural heritage of the Baraba Tatars is very timely.

The examples in the collection are given in the transcription developed by V.V.Radlov, which contributes to the scientific significance of the book. V.V.Radlov used a special type of transcription in the Cyrillic alphabet as well as specific symbols used to better express the features of the Baraba Tatars' language. Even after a hundred and fifty years, his transcription can show the melody of the authentic speech of those times. This method enabled the scholar to preserve all features of the language for the next generations. Hopefully, the tune, the melody of the dying Baraba Tatars' speech will be saved in the written form owing to the examples of the collection.

The book differs from other collections as it has Russian translations of authentic speech examples. The fact that the texts are given in two languages enhances its importance for both philological and culturological research. Moreover, it is socially and psychologically significant for the Russians living among the Tatars. The authors set the following goals. The first is to acquaint people, who believe themselves to be Baraba Tatars without knowing their own language, with their national genius and character; the second is to introduce the dying cultural property of Baraba Tatars to as many people as possible. The authors managed to cope with the difficulties of translating folkloristic texts. The examples of the book, containing cultural facts specific to this ethnic group only, are presented in a way which makes them comprehensible and easy to understand by people with a different mentality. The translators should know all the peculiarities and details of the given examples of Baraba Tatars' speech, recorded in different periods, to reveal the meaning of every single word, suffix and particle, they should feel "the breathing" of the language. All this requires a profound theoretic knowledge and a great experience in transcribing and translating ancient linguistic phenomena which are not found in the literary language or other dialects; obsolete for Baraba Tatars' speech but preserved in folkloristic texts. The authors of the book coped with this task.

According to the great scholar L.N.Gumilev, some Turkic people, even though not connected in any way, can understand each other's language, and this is a unique phenomenon. The scholars consider Siberian Tatars' colloquial language to be the dialect of the Tatar language. Baraba Tatars learned to read the Tatar literary language in Soviet times. Over the last years the connections with the Volga region Tatars have become less close and the influence of their literary language has significantly decreased. It is a great regret that this ethnic group with its rich cultural heritage, long history and language and preserved ancient linguistic phenomena is dying.

The book *Baraba Tatars. Chapters of Intellectual Culture* contains a collection of unique mental artifacts of Turkic people, dastans. Some of them are published with the variations preserved by Baraba people. The authors explain it by the fact that this epic-lyrical genre has been preserved by Siberian Tatars, who live far from busy highways, particularly in Baraba region. Besides, these works have a stable form and structure. In the second half of the 19th century, V.V.Radlov wrote down one Baraba Tatar's full variation of the dastan *Idegay*. Even this single fact testifies to the scientific value

of the cultural heritage belonging to our kindred ethnic groups which are losing their place in history.

The toponymy of different regions is a sphere which demands special research and various studies. Through these we can acquire information about the origin, history and language of the people living in a certain place. The authors of the collection *Baraba Tatars. Chapters of Intellectual Culture* have also highlighted this interesting phenomenon: the whole chapter is devoted to the Turkic-Tatar toponymy of the Novosibirsk region. The meaning of every term is clarified and its origin is given. The chapter contains the names of the villages the Tatars used to live in, thus, they still preserve their Tatar denominations. At the end of the book there is a reference list of toponyms in alphabetical order. The microtoponymy of numerous villages is given and explained in the book as well as hydronyms of the region rich in rivers and lakes.

Although most of the work is devoted to oral folk arts, there is also information about the traditional ceremonies for people's lives, the seasons, and nature, the rites and traditions connected with important events in every person's life, such as a wedding ceremony and a funeral. There are also texts about the cult of dolls which some groups of Baraba Tatars used to practice even after the adoption of Islam. At the end of the book, there are literary and publicistic notes, travel essays and manuscripts of educated Tatars from Baraba. All this testifies to the fact that there were people among Baraba Tatars who knew the Arabic language and the literary language of that period.

The book throws light upon Baraba Tatars' history, the language peculiarities of this dialect, and the history of Baraba Tatars' studies; it also provides comprehensive information about the folklore of the region. In other words, besides its scientific significance, the book is of great practical value. The texts collected in the book are, on the one hand, a good folkloristic source, and on the other hand, they can be used in training Tatar philologists and help students notice and learn the phonetic, lexical, and grammatical peculiarities of the Baraba dialect. This collection can thus provide irreplaceable assistance for students working on their course papers and diplomas as well as for young researchers. Oral folk arts may partially be conveyed to the people through folk music groups.

People did not only hand down their creations from generation to generation, but changed them by adding something new. The book *Baraba Tatars. Chapters of Intellectual Culture* has numerous examples of these phenomena in different genres, such as variations of the dastan *Ajtuka*, contributed by L.V.Dmitrieva and M. Sadri, which they recorded during their expedition with the assistance of F.Yu.Yusupov. These variations differ from each other in content, length, and rhythmic pattern. Therefore, the character of Ajtuka, born a hero of the masses, has been created by different generations and is still alive. His name is associated with eternal love and moral purity, the remainder of the ancestors. According to the references given in the book, nowadays, the dastan *Ajtuka*, which has 20 variations, is one of the most favourite oral folk art creations both with young and old people. This means that a real work of art is eternal.

The book presents songs under the same name and with different content, for example, *Taptilau* and *Taftilau*. These songs have the same first line, however with a different meaning. The variation written down by L.V.Dmitrieva:

*Kazanda tugel, jok Maskauda*

*Bu Taptilau jyurlaryun yurlagan. (Neither in Kazan, nor in Moscow There is anyone who has sung this Taptilau song.)*

Another variation:

*Kazanda guna tugel, Maskauda da*

*Bu Taftilau kojyo jurlangan (Not only in Kazan but even in Moscow This Taftilau song has been sung.)*

The phenomena of variety found in the dialect language are reconstructed in the book as the property of the people. For example, there are some variations of the time-phrase *boryn-boryn zamanda* (once upon a time) in the fairytales written down by L.V.Dmitrieva: the fairytale *An Old Man's Son* has *puryn-puryn samanda*, in *Katicha* we find *poron-poron samanta*, and in the fairytale *Peri – boryn samanda*. It was transcribed as *poryn-poryn zamanta* in the fairytale *Karagush* written down by D.G. Tumasheva, and *purungu samanda* in the legend published in V.V. Radlov's work *The Examples of Folk Literature of Turkic Tribes*. Variations can be found within the same text. For example, the girl's name has two variants in the legend about Baraba: *Baarchyn* and *Paarchyn*. Obviously, the Baraba dialect has speech variants although the scholars do not admit it. The work *Baraba Tatars. Chapters of Intellectual Culture* provides the opportunity to notice these phenomena.

To conclude, we can say the following: the collection *Baraba Tatars. Chapters of Intellectual Culture* has made a contribution to Tatar folklore, language, history, and ethnography; it will assist in

developing the theatrical and amateur art of Tatar people; and it can be considered a step forward in the research into Turkic peoples' history, and their mental and cultural property.

# «БАРАБИНСКИЕ ТАТАРЫ. СТРАНИЦЫ ДУХОВНОЙ КУЛЬТУРЫ. Ф.Ю.ЮСУПОВ, Ф.С.САЙФУЛИНА, О.Р.ХИСАМОВ, И.Г.ГУМЕРОВ» (КАЗАНЬ: КАЗАН. УН-Т, 2013, 668 С.) КИТАБЫНА БӘЯЛӘМӘ

**Гафур Мәсгут улы Сөнгатов,**
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге,
Россия, 420015, Казан ш., Пушкин ур., 66/33нче йорт,
gsungatov@mail.ru.

**Фәнзилә Хәким кызы Җәүһәрова,**
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге,
Россия, 420015, Казан ш., Пушкин ур., 66/33нче йорт,
fanzila@bk.ru.

Ф.Й.Йосыпов, Ф.С.Сәйфулина, О.Р.Хисамов һәм И.Г.Гомәровлар тарафыннан төзелгән «Барабинские татары. Страницы духовной культуры» дигән китапта, себер киңлекләрендә яшәүче бараба татарларының этник тарихына, тел үзенчәлекләренә, йолаларына, тормыш-көнкүрешләренә караган кызыклы үрнәкләр белән беррәттән, бараба татарларының формалашуын, аларның Көнбатыш Себер туфракларын үз ватаннары итеп сайлаган башка төрки кавемнәр белән бик борынгы заманнардан тыгыз элемтәләрдә яшәүләрен аңлатуга багышланган фәнни-аналитик мәкалә дә урын алган. Җыентык, авторларның төрле елларда үзләре туплаган материаллардан тыш, В.В.Радлов, Л.В.Дмитриева, Д.Г.Тумашева кебек галимнәрнең монографияләреннән алынган текстлар һәм композитор А.Ключарев язып алган җырлар белән баетылган. Саны елдан-ел кимү сәбәпле, Россиянең югалып бара торган халыклар исемлегенә кертелгән бараба татарларының җанлы сөйләм үрнәкләрен үз эченә алган әлеге тупланма киң карашлы, тирән белемле татар филологларын әзерләгәндә, бараба диалектының фонетик, лексик, грамматик үзенчәлекләрен тулы рәвештә күрергә һәм өйрәнергә мөмкинлек бирсә, тарихчыларга теге яисә бу фактны дәлилләү чыганагы, этнографларга, халыкның рухи хәзинәсен өйрәнүчеләргә әһәмиятле хезмәт буларак бәяләнә.

**Төп төшенчәләр:** фольклор, себер татарлары, татар теле, тел үзенчәлекләре, рухи мәдәният.

Гуманитар фәннәр өлкәсендә халыкның, шул исәптән аның этник төркемнәренең телен, көнкүреш үзенчәлекләрен, фольклорын саклау максаты белән төзелгән җыентыклар милләтнең тарихи барыштагы үзгәрешләрен күзәтү ягыннан әһәмиятле чыганак буларак бәяләнә башлады. Әйтергә кирәк, бүгенге көндә тел, әдәбият белемнәре, фольклористика галимнәре тарафыннан күмәк хезмәт буларак нәшер ителгән китаплар татар филологиясе фәнендә дә лаеклы урын ала башладылар. Мәкаләдә нәкъ шундый җыентыкларның берсе «Бараба татарлары. Рухи мәдәният битләре» бәяләнә. Тупланманы төзүче авторларның берсе – бу эшкә үзенең алтмыш еллап хезмәтен багышлаган Ф.Й.Йосыпов – кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен әзерләгән вакытта татарлар яшәгән барлык төбәкләрне йөреп чыккан, җанлы сөйләмне үз кулы белән язып алып, кыйммәтле фактик материал туплаган һәм анализ нәтиҗәләрен күпсанлы фәнни хезмәтләрендә яктырткан галим. Ул татар диалектологиясенә диалект телен тикшерү дигән юнәлешне алып килде һәм, төрки тел белемендә беренче булып, шул яссылыкта тикшеренүләрне башлап җибәрде. Ф.Й.Йосыповның татар диалект теленең грамматикасын бердәм система буларак карап, лингвистик география һәм чагыштырмалы-тарихи методларны кулланып язылган хезмәтләре һәм аерым татар сөйләшләренең фонетикасын, лексикасын һәм грамматикасын тулы рәвештә тасвирлаган монографияләре төрки тел белеме үсешенә лаеклы өлеш керттеләр. Икенче автор – Ф.С.Сәйфулина – шактый еллар Тобол педагогия институтында укытып, һәр көн себер татарлары сөйләмен тыңлап яшәгән әдәбиятчы галим. Тел белгече

О.Р.Хисамов һәм әдәбият галиме И.Г.Гомәровлар да бу китапны чыгаруда зур көч куйганнар. Әлеге тупланма бараба татарларының этник тарихын, тел үзенчәлекләрен, йолаларын, тормыш-көнкүрешен, гомумән, башка төрки халыкларның килеп чыгышын, тел үсешен һ.б. ларны өйрәнү юлында файдалы чыганак буларак та бәяләнергә хаклы.

Себер татарларының диалектларын өйрәнгән күренекле галимә Д.Г.Тумашева билгеләгәнчә, бараба диалекты өч себер татар диалекты арасында урталыкны тәшкил итә: анда тобол-иртыш диалекты билгеләре дә, том диалекты үзенчәлекләре дә чагылыш таба, шул ук вакытта борынгылык күренешләре дә саклана. Галимнәр тарафыннан бараба татарларының диалекты гасырлар буена татар телен борынгы төрки тел белән тоташтырып торган күпер буларак билгеләнә.

Бараба татарларының җанлы сөйләм үрнәкләре һәм халык авыз иҗаты ядкәрләре төрки халыкларны өйрәнүдә тирән эз калдырган В.В.Радлов тарафыннан XIX гасырда ук язып алына башлаган. Галимнең бу хезмәтләре үз заманында ук бәясен алды. Тәкъдим ителгән әлеге җыентыкның тагын бер әһәмиятле ягы – галимнәр төрле чорларда туплаган халык хәзинәсен бер принципта бөтенлекле туплап бастыру. Китапта В.В.Радловның тупланмаларындагы үрнәкләр, тел белгечләре Л.В.Дмитриева, Д.Г.Тумашева һәм башка татар диалектологлары хезмәтләрендәге текстлар, А.Ключарев язып алган җырлар, 1940 елгы экспедициядә катнашкан шагыйрь М.Садриның «Иртешкә сәяхәт» исемле китабында бирелгән ифрат кызыклы халык җырлары урын алган. Хезмәтнең Новосибирск төбәгендәге фән, мәгариф, мәдәният эшлекләләре арасында һәм өлкә җитәкчелегендә зур кызыксыну уятуы шуның белән аңлатыла да.

Китап бараба татарларының барлыкка килүен, аларның Көнбатыш Себер туфракларын үз ватаннары итеп сайлаган башка төрки кавемнәр белән бик борынгы заманнардан тыгыз элемтәләрдә яшәүләрен аңлатуга багышланган фәнни-аналитик мәкалә белән башланып китә. Биредә бараба татарларының аерым этнос буларак формалашуларындагы төп этаплар, аларның мәдәни-социаль хәлләре турында сөйләнә, әлеге кавемгә кагылышлы фәнни хезмәтләргә, историографик яссылыктан торып, күзәтү ясала.

Хезмәтнең кереш мәкаләсендә билгеләнгәнчә, бүгенге көндә бараба татарларының саны 8 000 кешедән артмый, бу күрсәткечкә XIX-XX гасырларда, Бараба далаларына күчеп килеп, җирле халык арасында яшәүче казан татарлары да кергән булырга тиеш. Кызганыч ки, аларның саны елдан-ел кими бара. Шуңа күрә күп кенә халыкара оешмалар бараба татарларын Россиянең югалып баручы халыклар исемлегенә кертеп карыйлар. Шушы вәзгыять күзлегеннән дә бараба татарларының рухи мирасына багышланган бу китапның әһәмияте зур.

Җыентыктагы үрнәкләрне галим В.В.Радлов тәкъдим иткән транскрипциядә бирү омтылышы аның фәннилеген тирәнәйтә. В.В.Радлов, бараба татарларының тел үзенчәлекләрен төгәлрәк чагылдыру өчен, кириллицага аерым билге-символлар өстәлгән махсус транскрипция куллана. Аның бу транскрипциясе, йөз илле ел вакыт үтүгә карамастан, шул заманнардагы җанлы сөйләмнең «яңгырашын» укучыга хәзер дә җиткерә ала. Әлеге методиканы куллану нәтиҗәсендә, галим телнең бар нечкәлекләрен киләчәк буыннарга консервацияләп калдыра алган. Җыентыкта урын алган үрнәкләрдә югалып баручы бараба татарлары җанлы сөйләменең яңгырашы, аһәңе язма формада сакланып калыр дигән өмет тә уяна.

Китап, җанлы сөйләм үрнәкләренең рус телендә тәрҗемәләрен бирү белән, башка җыентыклардан аерылып тора. Текстларның ике телдә булуы, филологик һәм культурологик яссылыктан караганда, җыентыкның гыйльми кыйммәтен арттыра. Ул гына да түгел, руслар арасында яшәүче татарлар өчен бу социаль-психологик әһәмияткә дә ия. Авторлар бу очракта берничә максатны күз алдында тотканнар. Беренчесе, үзләрен бараба татарлары дип исәпләп тә, телләрен белмәгән вәкилләргә халыкның рухын, менталитетын җиткерү; икенчесе, югалып баручы бараба татарларының мәдәни хәзинәсе белән мөмкин кадәр киң катлам укучыларны таныштыру. Китап авторлары текстларны тәрҗемә итүдәге авырлыкларны җиңеп, аны намус белән башкарып чыкканнар, чөнки фольклор әсәрләрен икенче телгә тәрҗемә итүнең аерым таләпләре бар. Ул үрнәкләрдә теркәлгән шушы халыкка (этник төркемгә) гына хас мәдәни

күренешне башка менталитетлы халык аңларлык итеп бирә белүдә чагылыш таба. Тәрҗемәчедән бараба татарларыннан төрле елларда язып алынган үрнәкләрнең асылын, нечкәлекләрен белү генә түгел, ә иң элек, бараба сөйләм теленең һәрбер сүзенең, һәрбер кушымча яки кисәкчәнең мәгънәсен белү, телнең «сулышын» тою сорала. Бу исә, әдәби телдә һәм башка диалектларда булмаган үзенчәлекләрне, хәтта бараба татарлары сөйләмендә искереп төшеп калган, ә фольклор әсәрендә сакланган борынгы күренешләрне аңлап транскрипцияләү һәм тәрҗемә итү ныклы теоретик белем һәм күпьеллык гамәли күнекмәләрне – зур эш тәҗрибәсе булуны таләп итә. Хезмәт авторлары бу эшне дә тиешле югарылыкта башкарып чыга алганнар.

Үз заманында бөек галим Л.Н.Гумилев әйткәнчә, төрки халыкларның кайберләре, гасырлар буена бер-берсе белән аралашмыйча яшәсәләр дә, үзара аңлаша алулары уникаль күренеш булып тора. Себер татарлары татар халкы составына кертеп карала, фәндә аларның сөйләм телләре татар теле диалектлары буларак билгеләнә. Бараба татарлары совет чорында татар әдәби телен өйрәнделәр һәм әдәби телдә укыдылар. Соңгы елларда Идел буе татарлары белән аралашу да, әдәби телнең йогынтысы да шактый кимеде. Бай рухи мирасы, зур тарихы булган, дастаннарга кадәр хәтерендә йөртеп, борынгы тел үзенчәлекләрен саклаган кавемнең юкка чыгып баруы бик кызганыч, әлбәттә.

«Бараба татарлары. Рухи хәзинә сәхифәләре» китабында төрки халыкларның кабатланмас рухи ядкәре – дастаннар – тупланмасы бирелгән, кайберләренең барабалыларда сакланган вариантлары да китерелгән. Әлеге лиро-эпик жанрның себер татарларында, аерым алганда, бараба төбәгендә саклануын китап авторлары алар яшәгән территориянең олы юллардан ераклыгы, шулай ук әсәрләрнең тотрыклы көе һәм тезмә калыбы булу белән бәйләп аңлаталар. XIX гасырның икенче яртысында В.В.Радлов «Идегәй» дастанының тулы бер вариантын бараба татарларыннан язып алган. Бу факт үзе генә дә тарихта эзләре җуелып барган кардәшләребезнең рухи мирасының фәнни кыйммәте турында сөйли.

Мәгълүм булганча, аерым төбәкләрнең топонимиясе махсус тикшерүне, күпкырлы эзләнүләрне таләп итә торган өлкә. Алар аркылы билгеле бер төбәктә яшәүче халыкның килеп чыгышы, тарихы, аның теле хакында бай мәгълүмат алып була. «Бараба татарлары. Рухи хәзинә сәхифәләре» җыентыгы авторлары да әлеге кызыклы тармакны читтә калдырмаганнар. Хезмәттә Новосибирск өлкәсенең төрки-татар топонимиясенә тулы бер бүлек багышланган. Анда һәр атама турында мөмкин кадәр тулы аңлатма бирелә, аларның килеп чыгышы аңлатыла, татарлар хәзер яшәмәгән, әмма татар теленә мөнәсәбәтле авыл исемнәре китерелә, соңыннан алфавит тәртибендәге исемлек урнаштырыла. Китапта күп кенә авылларның микротопонимиясе дә тупланган һәм аларга аңлатма бирелгән, елгаларга һәм күлләргә бай булган төбәкнең гидронимнары җыйналган һәм анализланган.

Хезмәтнең зур өлешен халык авыз иҗаты алып торуга карамастан, халыкның көнкүрешенә караган, ел фасылларына, табигатькә кагылышлы йолалар да, һәр кеше гомерендә була торган иң әһәмиятле вакыйгалар – бала туу, туй үткәрү һәм дөнья куйган кешене җирләүгә караган йолалар һәм гореф-гадәтләр дә урын алган. Биредә бараба татарларының кайбер төркемнәрендә халык Ислам динен кабул иткәннән соң да дәвам иткән курчакларга табыну күренешләрен тасвирлаган текстлар да урнаштырылган. Китап ахырында бараба татарлары арасыннан чыккан укымышлы татарларның әдәби-публицистик язмалары, сәяхәтләре, кулъязмалары китерелгән. Бу мисаллар барабалылар арасында гарәп телен яхшы белгән, шул чор татар әдәби телен үзләштергән зыялылар катламы булуы турында сөйли.

Бараба татарларының тарихын яктырту, әлеге диалектка караган тел үзенчәлекләренең килеп чыгышын һәм аларны өйрәнү тарихын чагылдыру, төбәк фольклоры хакында күләмле мәгълүмат бирү, ягъни фәнни әһәмиятен ассызыклау белән бергә, хезмәтнең гамәли кыйммәтен билгеләү дә мөһим. Киң карашлы, тирән белемле татар филологларын әзерләгәндә, китапта тупланган әсәрләр, бер яктан, бай фольклор чыганагы булып хезмәт итсәләр, икенче яктан, алар бараба диалектының фонетик, лексик, грамматик үзенчәлекләрен студентларга тулы рәвештә күрергә һәм өйрәнергә мөмкинлек бирә. Димәк, җыентык курс һәм диплом эшләре язучыларга, аеруча, фән юлын сайлаган яшь тикшеренүчеләргә эшләрен югары дәрәҗәдә башкарып чыгарга ярдәм итә торган алыштыргысыз кулланма була ала. Халык авыз иҗаты әсәрләренең бер өлеше фольклор-

сәнгать коллективлары аша халыкка җиткерү өчен хезмәт итәргә мөмкин.

Халык үзе иҗат иткән әсәрләрне буыннан-буынга тапшырып кына калмаган, һәр сөйләүче аңа нинди дер үзгәреш, өстәлмәләр кертә барган. «Бараба татарлары. Рухи хәзинә сәхифәләре» тупланмасында мондый күренешләр төрле жанрлар мисалында күзгә ташлана. Мәсәлән, китапка «Әйтүкә» дастанының Л.В.Дмитриева, М.Садрилар тарафыннан теркәлгән һәм Ф.Й.Йосыпов җитәкчелегендәге экспедиция вакытында язып алынган берничә варианты кертелгән. Алар эчтәлеге, күләмнәре һәм ритмик үлчәмнәре белән бер-берсеннән бик нык аерылып торалар. Димәк, халык каһарманы буларак туган Әйтүкә образы төрле чор буыннары тарафыннан иҗат ителеп, бүгенге көндә дә яшәвен дәвам итә. Аның исеме белән, мәңгелек саф мәхәббәт хисләренә, ата-бабалардан килгән әхлакый чисталыкка дан җырлана. Китапта бирелгән искәрмәләргә караганда, бүгенге көндә 20 варианты булган «Әйтүкә» дастаны картларның да, яшьләрнең дә иң яраткан халык авыз иҗаты әсәреләреннән санала, бу исә чын сәнгать үрнәкләренең мәңгелек икәнлекләре турында сөйли.

Җырлар арасында да, халыкта бер исем белән аталып та, эчтәлеге ягыннан уртаклыгы булмаганнарын күрергә мөкин. Мисалга «Тәптиләү» һәм «Тәфтиләү»не алыйк. Бу җырларда беренче юл гына туры килә, әмма анда да капма-каршы мәгънә китерелә. Л.В.Дмитриева теркәгән вариант:

*Казанда түгел, йок Мәскәүдә*
*Бу Тәптиләү йырларын йырлаган.*

Башка вариантта:

*Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә*
*Бу Тәфтиләү көйө йырланган*

Диалект теленең вариантлы күренешләргә байлыгы китаптагы халык мирасында ачык гәүдәләнә. Мәсәлән, Л.В.Дмитриева тарафыннан язып алынган әкиятләрдә күптәнге вакыт төшенчәсен белдергән *борын-борын заманда* сүзтезмәсе берничә язылышта бирелгән: «Бер картның улы» әкиятендә – *пурын-пурын саманда*, «Кәтичә»дә – *порон-порон саманта*, «Пәри» әкиятендә – *борын саманда*. Ул Д.Г.Тумашева теркәгән «Карагуш» әкиятендә – *порын-порын заманта*, В.В.Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен» хезмәтендәге риваятьтә *пурунгу саманда* формасында транскрипцияләнгән. Хәтта бер үк текстта да вариантлылык күзәтелә. Мәсәлән, Бараба турындагы риваятьтә хатын-кыз исеме ике язылышта очрый: *Баарчын* һәм *Паарчын* һ.б. Күренә ки, галимнәр бараба диалектын сөйләшләргә бүлмәсәләр дә, әйтелеш вариантлылыгы яшәп килә. Бу – диалект теле өчен гадәти күренеш. «Бараба татарлары. Рухи хәзинә сәхифәләре» хезмәте шундый үзенчәлекләрне берьюлы тотып алырга, күрергә мөмкинлек бирә.

«Бараба татарлары. Рухи хәзинә сәхифәләре» исемле җыентык хакындагы фикерләрне йомгаклап, түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин: хезмәт татар фольклоры, теле, тарихы, этнография фәннәренә зур өлеш кертә; татар халкының сәхнә культурасы, үзешчән сәнгать үсешенә ныклы ярдәм булып тора; төрки халыклар тарихын һәм рухи-мәдәни мирасны өйрәнү юлында зур бер адым буларак саналырга хаклы.

# РЕЦЕНЗИЯ НА КНИГУ «БАРАБИНСКИЕ ТАТАРЫ. СТРАНИЦЫ ДУХОВНОЙ КУЛЬТУРЫ. Ф.Ю.ЮСУПОВ, Ф.С.САЙФУЛИНА, О.Р.ХИСАМОВ, И.Г.ГУМЕРОВ» (КАЗАНЬ: КАЗАН. УН-Т, 2013, 668 С.)

**Гафур Масгутович Сунгатов,**
Республиканский центр традиционной культуры,
Россия, 420015, г.Казань, ул.Пушкина, д.66/33,
gsungatov@mail.ru.

**Фанзиля Хакимовна Завгарова,**
Республиканский центр традиционной культуры,
Россия, 420015, г.Казань, ул.Пушкина, д.66/33,
fanzila@bk.ru.

В составленном Ф.Ю.Юсуповым, Ф.С.Сайфулиной, О.Р.Хисамовым и И.Г.Гумеровым сборнике «Барабинские татары. Страницы духовной культуры» наряду со сведениями об этнической истории, особенностях языка, обычаях, повседневной жизни барабинских татар, живущих на просторах Сибири, имеется научно-аналитическая статья об истории зарождения, обретения ими западно-сибирской земли в качестве родины и о взаимоотношениях с другими народами начиная с древних времен. Кроме материалов, собранных авторами сборника, издание дополнено текстами песен, записанными такими учеными, как В.В.Радлов, Л.В.Дмитриева, Д.Г.Тумашева, композитором А.Ключаревым – специалистом в области музыкального татарского фольклора. Это издание, в котором представлены образцы живой речи барабинских татар, принадлежащих к исчезающим народам России и чья численность уменьшается год от года, может быть использовано в подготовке филологов с глубокими познаниями в области татарской филологии, в то же время оно будет интересно историкам и этнографам, так как содержит сведения о сокровищах духовной культуры данной этнической группы.

**Ключевые слова:** фольклор, сибирские татары, татарский язык, духовная культура.